Республика Татарстан

СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22 март 2019 ел** **№97**

Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр мониторингын үткәрү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Карарга теркәлгән “Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне” расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы рәисе Н.Н.Хуҗина